КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 23 сентябрь г.Казань № 909

Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибе» 2014 ел, 25 ноябрь, 909 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 декабрь, 909 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 28 декабрь, 1067 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль

хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибе» 2014 ел, 25 ноябрь, 909 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 22 август, 677 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибе» 2014 ел, 25 ноябрь, 909 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 7 сентябрь, 798 нче.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин